ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 04 2026 г. № 447

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының 2026 елның II кварталына нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган, «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак һәм торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыруда ярдәм итү» федераль проектының яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чарасы кысаларында Түбән Кама муниципаль районында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куелган, күрсәтелгән түләүләр торак урыннарны сатып алуга (төзүгә) федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелә торган яшь гаиләләр өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2026 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе турында» 2026 елның 24 мартындагы 177 номерлы боерыгына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге буенча 2026 елның II кварталына torakның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын 153 313 (йөз илле өч мең өч йөз унөч) сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Латыйпов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651041874